КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 9 декабрь г.Казань № 1130

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының территориаль органнарын үзгәртеп оештыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының территориаль органнарын үзгәртеп оештыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 1 июль, 534 нче карарының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип санау хакында

Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү, шулай ук дәүләт мөлкәтеннән нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе системасын оптимизацияләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының дәүләт учреждениеләре булган түбәндәге территориаль органнарын (алга таба – территориаль органнар) аларны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына тоташтыру юлы белән үзгәртеп оештыру турындагы Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тәкъдимен кабул итәргә:

«Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Казан шәһәре муниципаль берәмлеге буенча идарәсе» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча идарәсе» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе;

«Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Зеленодольск муниципаль районы буенча идарәсе» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы аңа тапшыру актлары нигезендә кушылучы үзгәртеп оештырыла торган территориаль органнарның хокукый дәвамчысы булып тора дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

гамәлдәге законнар нигезендә территориаль органнарны үзгәртеп оештыруга бәйле чаралар үткәрергә;

территориаль органнарны үзгәртеп оештыруга бәйле рәвештә, эштән азат ителүче хезмәткәрләргә гарантияләрне һәм компенсацияләрне тәэмин итәргә;

территориаль органнарны үзгәртеп оештыру чараларын 2019 елга Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгын карап тотуга каралган акча исәбеннән финанслауны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына үзгәртеп оештырыла торган территориаль органнарга элегрәк беркетелгән күчемле һәм күчемсез мөлкәт объектларын, җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына билгеләнгән тәртиптә беркетергә.

5. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карарының 4 нче пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының территориаль органнарын үзгәртеп оештыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 1 июль, 534 нче карарының 5 нче пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацлары.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин